| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2021 Баулы шәһәре № 80

«2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Баулы муниципаль районында ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы нигезләмә нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проектын хупларга һәм фикер алышуга, шул исәптән ачык тыңлауларга куярга (1 нче кушымта).

2. Карар проектын 1 нче кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә.

3. Түбәндәгеләрне расларга:

1. «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында» Баулы муниципаль районы Советы

карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен (2 нче кушымта);

- «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибен (3 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга:

- «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проектын (1 нче кушымта);

- «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен (2 нче кушымта);

- «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибен (3 нче кушымта).

5. «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча килгән тәкъдимнәрне гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемне түбәндәге составта төзергә:

1. Шакирҗанов Дамир Әхтәм улы - эшче төркем рәисе.

2. Сафина Эльвира Әнис кызы - эшче төркем әгъзасы.

3. Свежинкина Лилия Салихҗан кызы - эшче төркем әгъзасы.

6. «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2021 елның 19 ноябрендә 16.00 сәгатьтә Баулы муниципаль районы башкарма комитетының утырышлар залында (Татарстан Республикасы, Баулы районы, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт) уздырырга.

7. Эшче төркемгә «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы депутатлары һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Баулы муниципаль районы Советы каравына чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Баулы муниципаль районы бюджеты турында 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
район Советы Рәисе вазыйфасын
башкаручы – район башлыгы
урынбасары, район Советы
Рәисе урынбасары Р.Г. Хәмидуллин